ГЛАВА САХАРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ САХАРОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

с. Сахаровка

**16.12.2024г** **№ 18**

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Сахаровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 һәм 39 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында «2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2023 елның 29 декабрендәге 1743 номерлы карарының 4.2 пункты белән җәмәгать фикер алышуларын яисә гавами тыңлауларны оештыруны һәм уздыруны җирле үзидарәнең җәмәгать фикер алышуларын яисә гавами тыңлауларны уздыруга вәкаләтле органы тәэмин итә. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Сахаровка авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Сахаровка авыл җирлегендә иҗтимагый фикер алышуларны яисә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә белән, авыл җирлегендә яшәүчеләрнең гавами тыңлаулар үткәрү юлы белән проект буенча фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатларында

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының

«Сахаровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Билгеләргә:
- гавами тыңлауларны оештыручы дип – Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Сахаровка авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләрен әзерләү комиссиясен (1 нче кушымта)
- үткәрү вакыты -2025 елның 06 гыйнварында, 10.00 сәгатьтә.
- үткәрү урыны-Сахаровка авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы, адресы: Татарстан Республикасы, Алексеевск муниципаль районы,Сахаровка авылы,Мирная урамы, 100 йорт.

3.Фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2025 елның 05 гыйнварына кадәр эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Татарстан Республикасы, Алексеевск муниципаль районы, Сахаровка авылы, Мирная урамы,100 йорт,язма рәвештә.

4.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Сахаровка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территорияләрендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясенә:
- гамәлдәге законнар нигезендә проект турында фикер алышу буенча гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга;
Гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен бастырып чыгарырга;
- Татарстан Республикасында җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясенә гавами тыңлаулар беркетмәсен, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә кертергә;
-әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырып халыкка җиткерергә.
- Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Сахаровка авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы К.А. Мигушинага йөкләргә.

Сахаровка авыл җирлеге
Советы утырышында рәислек
итүче 1 нче сайлау округы депутаты Н.И. Леденцов

Кушымта № 1

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Сахаровка авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе составы**

| ФИА | Вазыйфа |
|---|---|
| Мигушина Ксения Алексеевна | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Сахаровка авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы-комиссия рәисе. |
| Янбаева Ольга Михайловна | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Сахаровка авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре-комиссия секретаре. |
| Павлова Эльвира Нургаеновна | Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе. |
| Левина Евгения Юрьевна | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Сахаровка авыл җирлеге Советы депутаты-комиссия әгъзасы (килештерү буенча). |
| Шаброва Екатерина Владимировна | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Сахаровка авыл җирлеге Советы депутаты-комиссия әгъзасы (килештерү буенча). |